1948 нче елның 1 январенда Бондюг районы Бәзәкә авылында гомер кичерүче Хәмәт абый белән Миниса апа гаиләсендә гаиләгә ямь, өйгә нур өстәп җиденче бала дөньяга аваз сала. Бу ир балага Әнвәр дип исем бирәләр. Әнвәр кечкенәдән хәрәкәтчән , тапкыр телле булуы белән башка балалардан аерылып тора. Мәктәпкә укырга кергәч тә телгә осталыгын күреп стенгазета редакторы итеп билгелиләр аны. Рәхәтләнеп, бирелеп башкара бу вазифаны Әнвәр. Стенгазетаның һәр санын шигырьләр белән чыгара башлый ул. Шулай итеп иҗатка кереп китә. Ул елларда тау башына урнашкан Бәзәкә урта мәктәбендә күрше-тирә авыл балалары да килеп белем ала, икешәр смена укыткан мәктәптә класстан тыш чаралар - кичәләр дә еш үткәрелә. Язганнарын укырга үзенең кыюлыгы җитмәгәнгә бу кичәләрдә аның шигырьләрен классташы Рәмзия Гыймазетдинова кычкырып укый. Укытучысы Рәшит абый Башаров та егетне “күңелеңдә иҗат очкыны бар, язуыңны ташлый күрмә, киләчәккә максатларны шул юнәлештә билгелә” дип җилкендереп тора. Язган саен каләме шомара бара, шигырьләре район газетасында гына түгел, республика газеталарында да басылып чыга аның.

Шуңа күрә, Бәзәкә урта мәктәбен уңышлы тәмамлаганнан соң Әнвәр һич икеләнүсез башкалабыз Казанга юл ала. Хыялы – журналист булу. Ләкин... кызганычка каршы, хыял - хыял гына булып кала шул. Журналистика факультетына конкурстан уза алмыйча кире авылга әйләнеп кайтырга мәҗбүр була ул. Менделеевскида автошколада укыганнан соң армиягә алына. Ватан алдындагы хәрби бурычын Төркмәнстанның Чарджау шәһәрендә үти. Иҗаты өчен бик уңышлы чор була бу. Яшьлек дәрте ташып торганмы, өзелеп сагыну булганмы, уйланулар нәтиҗәсеме – язганнарының күбесе шушы елларга туры килә. Алар бертуган абыйсы Җәүдәт белән хәтта хатларны да шигырь формасында язышалар бу елларда.

Армиядән кайткач Менделеевскида автошколага инструктор-укытучы булып эшкә керә. Автошкола Чаллыга күчерелгәч ОРС ка шофер булып урнаша. Шатлык – куанычлары, борчу – мәшәкатьләре белән тормыш дәвам итә.

1972 нче елның 28 нче декабрендә авылдашы Гарифуллина Мөнҗия Галиәхмәт кызы белән гаилә корып җибәләр алар. Бәхетле яшь гаиләгә сөенеч өстәп бер-бер артлы 2 уллары – Ильнур белән Иршат туа...

Авылда бөтен нәрсә күз алдында, һәркемнең ничек яшәгәнен күреп-белеп торалар. Мин дә күп еллардан бирле Әнвәр абыйның шигырләр язуын ишетеп белә идем. Үзем шигырьләр яратканга күрә минем аның шигырьләрен укып карыйсым килә иде. Шигырьләрен , фикерләрен кемнәрдер үзләштергән, шуңа күрә ул язганнарын беркемгә дә күрсәтми икән дигән сүзләр дә ишеткәнем булды. Бу сүзләр минем кызыксынуны тагын да арттырды. Китапханәдә Мәдәният елы уңаеннан “Һәр күңелдә шигырь уты яна” дигән кичәгә әзерләнгәндә кыяр – кыймас кына Әнвәр абыйның тормыш иптәше Мөнҗия апага чылтыраттым. “Шигырьләре бар, килеп ал” дигән сүзләрне ишеткәч сөенечтән нишләргә белмәдем. Ниһаять, ничәмә - ничә еллар мине кызыктырган хыял минем кулда. Саргаеп беткән битләрне сак кына актарам... Аңлавымча, Киргизиянең Чарджау шәһәрендә хезмәт

иткәндә башланган дәфтәр. Ә шигырьләре, чынлап та, күңелне кузгатырлык.

Зәңгәр күзләреңә бу кадәрле
Ялкын кайдан туган?
Карашыңа кеше сүзләренә
Сыймас назлар сыйган...

Шулкадәрле төбәп карамачы
Уңайсызлык тоям...
Олы сөю янган  күзләргә мин
Лаек түгел сыман...

Бу шигырь конкурска җибәрелгән булган. Һичшиксез,  билгеләнмичә калгандыр дип уйламыйм мин аны,  күңелне кузгатырлык шигырь. Әнвәр абыйның бу дәфтәрендә туган авылга, әти - әнисенә , табигатькә, авылның һәр савымчысына  аерым багышлап язылган шигырьләренә кадәр бар. Әлбәттә, бик күп шигырьләр мәхәббәт турында. Зәңгәр төс белән язылган ул шигырьләрнең күбесен яңадан кызыл төс белән йөртеп чыккан. Никадәрле назлы-нәзберек  булган бит аның күңеле һәм никадәр якты хыяллар белән тулы булган эчке дөньясы!

Әнвәр абый шулай ук хикәяләр дә язган булган икән. Аннары бөек кешеләрнең канатлы сүзләрен дә язып куйган бу дәфтәргә. Газетада басылып чыкканнарын ябыштырып куйган. Бу дәфтәрне укыганнан соң мин Әнвәр абыйның никадәр нечкә хисле,  уйлы – гамьле кеше булуын аңладым. Шундый ялкынлы шигырьләр язган кешенең күңелендә шигырь уты ничек кенә янгандыр әле... Бәлки, шулай янып яшәгәнгә күрәдер, безнең арадан бик иртә китте Әнвәр абый. (2012 нче елның 17 ноябрендә инфаркттан вафат булды)

Борынгылардан калган “әтиең исән чакта һөнәрен өйрән, үлгәч - куәтен исеңдә тот” дигән  бер әйтем бар. Әнвәр абый да әтисеннән күреп үскәнгәдер, балта эшенә оста иде. Челтәрле тәрәзә йөзлекләре ясап туган авылы урамнарын  бизәде, авылдашларны сөендерде. Бу гаиләдә буыннар чылбыры өзелми. Бүгенге көндә бабасы белән әтисенең эшен улы Иршат дәвам итә. Бәлки, киләчәктә иҗат эшен дәвам итүче  нәсел дәвамчылары да булыр әле.

Ф.Башарова



“Кеше бөек! Кеше Матур! Горур!

Онытылып сөя белгәндә”



Әнвәр абый уллары Ильшат һәм Иршат белән



“Тик мин һәрчак тик үземчә хисле,

Кешенеке түгел - акыл да”



“Мин кем икән...

-Син кем? - диләр”



Төрекмәнстан...якты кояшлы ил



Урта мәктәп укучысы Әнвәр Зиннәтуллин
















ТАТАРСТАН



ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!

# ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

шоферу ЗИННАТУЛЛИНУ А.Х.

За высокие показатели достигнутые в служебной подготовки в 1978 учебном году и добросовестное выполнение служебного долга

НАЧ.ВПЧ-26
МАЙОР В/С [illegible]МЫРКИН

12/I-79г.

СЕКР.ПАРТ.
ОРГ.ВПЧ-26 Д.Г.ЗАЛЯЛУТДИНОВ




*За нашу Советскую Родину!*

# ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

ЦЕНТРАЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДОСААФ СССР

Н А Г Р А Ж Д А Е Т

*тов. Зинатуллина*

*Анвара Хаматовича.*

ЗА БОЛЬШУЮ И ПЛОДОТВОРНУЮ РАБОТУ ПО ПОДГОТОВКЕ СПЕЦИАЛИСТОВ ДЛЯ ВООРУЖЕННЫХ СИЛ СССР И НАРОДНОГО ХОЗЯЙСТВА И АКТИВНОЕ УЧАСТИЕ В ВОЕННО-ПАТРИОТИЧЕСКОМ ВОСПИТАНИИ МОЛОДЕЖИ.

ПРЕДСЕДАТЕЛЬ РЕСПУБЛИКАНСКОГО
КОМИТЕТА ДОСААФ ТАТ.АССР
ПОЛКОВНИК — Г.ШАКИРОВ

" *10* " апреля 1970 г.

ВСЕСОЮЗНОЕ ОРДЕНА КРАСНОГО ЗНАМЕНИ
ДОБРОВОЛЬНОЕ ОБЩЕСТВО СОДЕЙСТВИЯ
АРМИИ, АВИАЦИИ И ФЛОТУ

# ГРАМОТА

НАГРАЖДАЕТСЯ ПРЕПОДАВАТЕЛЬ МЕНДЕЛЕЕВСКОЙ АВТОМОБИЛЬНОЙ ШКОЛЫ ДОСААФ

тов. ЗИНАТУЛЛИН АНВАР ХАМАТОВИЧ

ЗА УСПЕХИ, ДОСТИГНУТЫЕ В ПОДГОТОВКЕ СПЕЦИАЛИСТОВ ДЛЯ ВООРУЖЕННЫХ СИЛ СССР В 1974-1975 УЧЕБНОМ ГОДУ.

Председатель
Татарского обкома ДОСААФ г. Шак (Г.ШАКИРОВ)

"22" сентября 1975 г.

ВСЕСОЮЗНОЕ ОРДЕНА КРАСНОГО ЗНАМЕНИ
ДОБРОВОЛЬНОЕ ОБЩЕСТВО СОДЕЙСТВИЯ
АРМИИ, АВИАЦИИ И ФЛОТУ

# ГРАМОТА

ТОВ.ЗИНАТУЛЛИН АНВАР ХАММАТОВИЧ

ПРЕПОДАВАТЕЛЬ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО АВТОМОТОКЛУБА ДОСААФ — НАГРАЖДАЕТСЯ ЗА УСПЕХИ, ДОСТИГНУТЫЕ В ПОДГОТОВКЕ СПЕЦИАЛИСТОВ ДЛЯ ВООРУЖЕННЫХ СИЛ СССР В 1972-1973 УЧЕБНОМ ГОДУ.

И.О.ПРЕДСЕДАТЕЛЯ ТАТАРСКОГО
ОБЛАСТНОГО КОМИТЕТА ДОСААФ — /С.ГОЛЬЦ/

17 сентября 1973 года.

ВСЕСОЮЗНОЕ ОРДЕНА КРАСНОГО ЗНАМЕНИ
ДОБРОВОЛЬНОЕ ОБЩЕСТВО СОДЕЙСТВИЯ
АРМИИ, АВИАЦИИ И ФЛОТУ

# ГРАМОТА

ТОВ. ЗИНАТУЛЛИН АНВАР ХАМАТОВИЧ –

ПРЕПОДАВАТЕЛЬ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО АВТОМОТОКЛУБА ДОСААФ

НАГРАЖДАЕТСЯ

ЗА УСПЕХИ, ДОСТИГНУТЫЕ В ПОДГОТОВКЕ СПЕЦИАЛИСТОВ ДЛЯ ВООРУЖЕННЫХ СИЛ СССР в 1973–1974 УЧЕБНОМ ГОДУ.

И.о. председателя Татарского
областного комитета ДОСААФ С.Б.ГОЛЬЦ

20 сентября 1974 года